ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2020 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар 2020 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә закон проектларын үз вакытында әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүне тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 24 декабре
№ 238-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2019 елның 24 декабрендәге
238-VI ДС номерлы карарына
кушымта

**2020 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында**
**закон проекты эшенең якынча планы**

| № т/б | Проектның исеме | Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъект | Проектны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру вакыты |
|---|---|---|---|
| | **1. Дәүләт корылышы** | | |
| 1 | «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (коррупциягә каршы тору чараларын законнар белән җайга салуны, шул исәптән коррупциягә каршы белем бирүне камилләштерү максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты И.И. Бикеев | I квартал |
| 2 | «Татарстан Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты И.И. Бикеев | II квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруның рәвешләрен һәм тәртибен законнар белән җайга салуны камилләштерү максатында) | | |
| 3 | «Татарстан Республикасы законнары мониторингы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы законы паспортына кертелергә тиешле белешмәләр исемлеген төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты | II квартал |
| 4 | «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре бирү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А. Чубаров | III квартал |
| 5 | «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (кулланылыштагы терминологияне «Фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәт турында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль закон терминологиясенә туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты | IV квартал |
| 6 | «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (кулланылыштагы терминологияне бюджет законнарында һәм административ хокук бозулар турындагы законнарда кулланыла торган терминологиягә туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (аерым нормаларны «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закондагы үзгәрешләргә туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе | IV квартал |
| 8 | «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты турында» 2004 елның 26 февралендәге 2632 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты (Татарстан Республикасы законнарына туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ш.Ш. Яһудин | IV квартал |
| **2. Икътисадый сәясәт** | | | |
| 9 | «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын түләүсез кую өчен урыннар бүлеп бирү тәртибен төгәлләштерү өлешендә федераль законнарга туры китерүгә юнәлдерелгән) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты | I квартал |
| 10 | «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | законы проекты (җир асты байлыкларыннан файдалануның төрләрен һәм вакытларын билгели торган, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның бурычларын, җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану һәм аларны саклауның төп таләпләрен билгели торган нигезләмәләргә төзәтмәләр кертү өлешендә) | Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | |
| 11 | «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге вәкаләтләрен төгәлләштерү, шулай ук гадәттән тыш хәлләрне кисәтүне һәм бетерүне финанс белән җайга сала торган нигезләмәләргә төзәтмәләр кертү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | I квартал |
| 12 | «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (редакция ягыннан үзгәрешләр кертү һәм терминологик төгәлсезлекләрне бетерү максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты | I квартал |
| 13 | «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (газ-мотор ягулыгындагы автобуслар һәм йөк автомобильләре өчен транспорт салымы буенча салым ташламасы бирү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Б. Мугерман | I квартал |
| 14 | «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 14 пунктына | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (күрсәтелгән мөлкәтне исәпкә алу аеннан башлап ташлама бирү тәртибен төгәлләштерү өлешендә) | Р.Б. Мугерман | |
| 15 | «2019 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $97^4$ статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | II квартал |
| 16 | «2019 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $97^6$ статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | II квартал |
| 17 | «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты | III квартал |
| 18 | «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | IV квартал |
| 19 | «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | IV квартал |
| 20 | «Татарстан Республикасында органик продукция турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | |
| **3. Социаль сәясәт** | | | |
| 21 | «Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына йөрмәүче 1,5 яшьтән алып 3 яшькәчә балалары булган гаиләләргә пособиеләр бирү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (мәктәпкәчә мәгариф учреждениесендә урын алу өчен исәпкә баскан, әмма мәктәпкәчә мәгариф учреждениесендә урын белән тәэмин ителмәгән 1,5 яшьтән алып 3 яшькәчә балалары булган ата-аналарга компенсация бүлеп бирү максатларында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Н.М. Атласов, М.З. Гарифуллин, А.В. Комисаров, Х.Г. Миргалимов, А.В. Прокофьев, Ф.М. Сафин | II квартал |
| 22 | «Сугыш чоры балаларына дәүләт социаль яклау чаралары турында» Татарстан Республикасы законы проекты («сугыш чоры балалары» категориясендәге гражданнарны билгеләү һәм акчалата компенсация түләү максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Н.М. Атласов, М.З. Гарифуллин, А.В. Комисаров, Х.Г. Миргалимов, А.В. Прокофьев, Ф.М. Сафин | II квартал |
| 23 | «2021 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (патент нигезендә физик һәм юридик затларда хезмәт эшчәнлеген наем буенча гамәлгә ашыручы чит ил гражданнарының физик затлар керемено салым буенча теркәлгән түләүләре күләмен индексацияләү максатларында Россия Федерациясе субъекты законы белән тиешле календарь ел өчен хезмәт базарының региональ үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү максатында) | | |
| 24 | «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты | III квартал |
| 25 | «Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасында 2021 елга пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 4 пункты нигезендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 26 | «2021 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның $26^3$ статьясы нигезендә) | | |
| 27 | «2021 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның $26^3$ статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 28 | «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (29 яшькә кадәр булган беренче тапкыр эш эзләүче һөнәри белем бирә торган уку йортларын тәмамлаучылар өчен эш урыннарына мәҗбүри квота кертү турында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Е.И. Кузьмичева | III квартал |
| 29 | «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты («Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законы нормаларын актуальләштерү максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативалары** | | | |
| 30 | «Инновацион транспорт чаралары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (инновацион транспорт чараларын эксплуатацияләү өлкәсендә хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салу өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев | I квартал |
| 31 | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (калдыкларны эшкәртү өлкәсендә гамәлдәге производствоны саклап калу, эш урыннарын саклау, «Экология» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында максатчан күрсәткечләргә ирешү өчен тагын да уңайлырак шартлар тудыру максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Н.М. Атласов | I квартал |
| 32 | «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законның $61^4$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (бурычлы кулланган электр энергиясенә түләү буенча алыш-бирешләрне конкурс идарәчесе тарафыннан ризасызлык белдерүне тыюны законнар белән ныгыту максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Х. Сөләйманов | I квартал |
| 33 | «Сугыш чоры балалары турында» федераль закон проекты (Россия Федерациясенең барлык субъектлары өчен «сугыш чоры балалары» категориясендәге гражданнарның хокукый хәленә бердәм мөнәсәбәт булдыру максатында һәм аларга акчалата компенсация түләү хакында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Н.М. Атласов, М.З. Гарифуллин, | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | А.В. Комисаров,<br>Х.Г. Миргалимов,<br>А.В. Прокофьев,<br>Ф.М. Сафин | |
| 34 | «Россия Федерациясе Торак кодексының 155 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты (торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү буенча вакытында түләнмәгән бурычны кире кайтару буенча хокукларны (таләпләрне) өченче затларга бирүне тыюга кагылышлы статья нигезләмәләрен төгәлләштерү максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Х. Сөләйманов | I квартал |
| 35 | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручыларны билгеләп куюны законнар белән җайга салу максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Э.С. Шәрәфиев | II квартал |
| 36 | «Мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (мәктәпкәчә мәгариф учреждениесендә урын алу өчен исәпкә баскан, әмма мәктәпкәчә мәгариф учреждениесендә урын белән тәэмин ителмәгән 1,5 яшьтән алып 3 яшькәчә балалары булган ата-аналарга акчалата компенсациягә хокукны гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең барлык субъектлары өчен бердәм мөнәсәбәт тәэмин итү максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Н.М. Атласов,<br>М.З. Гарифуллин,<br>А.В. Комисаров,<br>Х.Г. Миргалимов,<br>А.В. Прокофьев,<br>Ф.М. Сафин | III квартал |
| 37 | «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (күчемсез мөлкәт объекты буенча торак-коммуналь хезмәт | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.Г. Нуриев | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | күрсәтүләр өчен бурычның юклыгы турындагы белешмәне дәүләт теркәвенә алу өчен документлар исемлегенә кертү максатында) | | |